УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ
«23» 06 2015г.

БОЕРЫК
№ 01-05/100-пр

Казан шәһәре

**Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенен дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын жайга салу буенча комиссиясе турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көр әш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын жайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын жайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенен дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын жайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне (№ 1 кушымта) расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз жаваплылыгымда калдырам.

Башлык Р.Р.Зиатдинов

Татарстан Республикасының
Үзйөрешле машиналар һәм
техниканың башка төрләре
техник торышына күзәтчелек
итү идарәсенең
23 июнь 2015 № 01-05/100-пр
боерыгына № 1 кушымта

**Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы указының 7 пунктын үтәү максатыннан эшкәртелде.

2. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль

законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы Законнарына, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычы булып:

а) Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләренең) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтларын кисәтү яисә җайга салу турында таләпләрне гамәлгә ашыруда, шулай ук аларның «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларын үтәүне гамәлгә ашыруда (алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр) һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликларын җайга салу турында таләпләр);

б) Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсендә (алга таба – Идарә) коррупцияне кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруда.

4. Комиссия Идарәдә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфаларын) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү белән бәйле мәсьәләләрне карый (билгеләү һәм азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тормышка ашырылучы дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән гайре).

5. Билгеләү һәм азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тормышка ашырылучы Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу турында таләпләрне үтәү белән бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча комиссияләр тарафыннан карала.

6. Комиссия Идарәнең норматив хокукый акты белән төзелә. Күрсәтелгән акт нигезендә Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана.

Комиссия составына Комиссия әгъзалары саныннан, Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалар саныннан Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе тарафыннан билгеләп куела торган Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары керә. Карарлар кабул иткәндә комиссиянең барлык әгъзалары тигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе урынбасары (Комиссия рәисе), Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар,

эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсенең коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), оештыру-хокук эшләре бүлеге дәүләт хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе билгеләгән башка бүлекчәләрдән дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе вәкиле;

в) эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле фәнни оешмалар һәм урта, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесе вәкиле (вәкилләре).

8. Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе Комиссия составына түбәндәгеләрне кертү турында карар кабул итә ала:

а) «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22[1] статьясы нигезендә Идарәдә төзелгән җәмәгать советы вәкиле;

б) билгеләнгән тәртиптә Идарәдә эш итүче профсоюз оешмасы вәкиле.

9. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 8 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе белән, фәнни оешмалар һәм урта, югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре белән, Идарә каршысында төзелгән җәмәгать советы белән, Идарәдә билгеләнгән тәртиптә эш итүче профсоюз оешмасы белән килешенү буенча Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе соравы нигезендә кертелә. Килешенү әлеге сорауны алган көннән соң 10 көн вакыт эчендә башкарыла.

10. Дәүләт органында дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләмәүче Комиссия әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

11. Комиссия составы Комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый ала торган мәнфәгатьләр конфликтлары килеп чыгу мөмкинлеген булдырмауны гамәлгә ашырырлык итеп формалаштырыла.

12. Комиссия утырышларында киңәш бирү тавышы белән түбәндәгеләр катнаша:

а) аның хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәве мәсьәләләре Комиссия тарафыннан карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм әлеге мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре дәүләт органында биләгән вазыйфага охшаш дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче, Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнүче ике дәүләт хезмәткәре;

б) дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; Комиссия тарафыннан каралучы мәсьәләләр буенча һәм

дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча аңлатма бирә алучы белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынган оешмалар вәкилләре; аңа карата Комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәре яисә теләсә кайсы комиссия әгъзасы үтенече нигезендә комиссия рәисенең Комиссия утырышына кимендә өч көн кала һәр анык очракта аерым кабул ителүче карары буенча – аңа карата хезмәт тәртибенә таләпләрне (һәм) яисә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәве турындагы мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәре вәкиле.

13. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Утырышларны Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары катнашында гына уздыруга юл куелмый.

14. Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда, Комиссия әгъзасының мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган шәхси турыдан-туры яисә читләтеп кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул бу хакта утырыш башланганчы хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта Комиссиянең әлеге әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

15. Комиссия утырышын уздыру өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

а) Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хокукый норматив актлары нигезендә уздырылган дәүләт хезмәткәре биргән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләрне таныклаучы тикшерү материалларын бирү:

дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган керемнәре, чыгымнары, милкәтләре турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрнең дөрес булмавы яисә тулы белешмәләр бирелмәве турында;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве хакында;

б) Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсенең коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи затына Идарәнең норматив-хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә кергән:

Идарәдә Татарстан Республикасы Президенты раслаган вазыйфалар исемлегенә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданның коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яисә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга, әгәр бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кертелгән

булса, дәүләт хезмәтеннән азат итү коненнән соң ике ел узганга кадәр ризалык бирүе турында гражданнын мөрәҗәгате;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр буенча үзенең хатынынын (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү мөмкин булмавы турында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең территориясендә аның счетлары (керемнәре) булган, чит ил банкында акчалары һәм кыйммәтле әйберләре саклана торган чит дәүләтнен һәм (яисә) чит ил финанс инструментлары булган, яисә аның ихтыярыннан яисә аның хатынынын (иренен) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярыннан тормаган шартлар буенча әлеге чит дәүләтнең законнары нигезендә компетентлы органнары тарафыннан кулга алынуы, куллану тыелуы белән бәйле рәвештә «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясенән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясенән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) файдалануны тыю турында» Федераль закон) таләпләрен үтәү мөмкин булмавы турындагы гаризасы;

в) Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе житәкчесенең яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын жайга салу турында таләпләр үтәлүне тәэмин итүгә яки дәүләт органында коррупцияне кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруга кагылышлы тәкъдиме.

г) Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе житәкчесенең дәүләт хезмәткәре тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә күзәтчелек хакында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 1 өлеше нигезендә бирелгән белешмәләрнең дөрес булмавы яисә тулы белешмәләр бирелмәве турында таныклаучы тикшерү материалларын бирү;

д) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64[1] статьясы нигезендә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт шартнамәсе яисә гражданлык-хокукый шартнамә төзү турындагы Идарәгә бирелгән хәбәрнамәсе, әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарә итүенең аерым функцияләре граждан дәүләт органында вазыйфа биләгән вакытта аның вазыфаи (хезмәт) бурычларына кермәгән булса, әлеге гражданга Комиссия

тарафыннан алдарак бу хезмәт мөнәсәбәтләренә һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керү тыелган яисә әлеге гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яки коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында аның тарафыннан эшләр башкаруга рөхсәт бирү мәсьәләсе каралмаган булса.

16. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы һәм шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

17. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсенең коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи затына бирелә. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның туган көне, торган урынының адресы, дәүләт хезмәтеннән киткәнче кадәр ике ел дәвамында биләгән вазыйфалары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешма урнашкан җир, аның эшчәнлеге характеры, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгәндә граждан тарафыннан башкарылган вазыйфаи (хезмәт) бурычлары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмага мөнәсәбәтле дәүләт идарәсе буенча функцияләре, шартнамә төре (хезмәт һәм гражданлык-хокукый), якынча аның гамәле вакыты, шартнамә буенча башкарылган (күрсәтелгән) эш (хезмәт) өчен түләү суммасы. Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсенең коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи заты мөрәҗәгатьне карап тикшерә, аның йомгаклары буенча «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге ФЗ-273 номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып мөрәҗәгатьнең асылы буенча дәлилле бәяләмә әзерләнә. Мөрәҗәгать, бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать кабул ителгәннән соң ике эш көне дәвамында Комиссия рәисенә бирелә.

18. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китәргә планлаштыручы дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелергә мөмкин һәм ул Комиссия тарафыннан әлеге Нигезләмәгә таянып каралырга тиеш.

19. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге ФЗ-273 номерлы «Коррупциягә каршы тору» Федераль законының 12 статьясы таләпләре үтәлүе турындагы дәлилле бәяләмәләрне әзерләү белән шөгыльләнүче Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсенең коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча бүлекчәсенең коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карап тикшерелә. Хәбәрнамә, бәяләмә һәм башка материаллар хәбәрнамә алынган көннән ун эш көне дәвамында Комиссия рәисенә бирелә.

20. Комиссия рәисе аңа дәүләт органы норматив-хокукый актында каралган тәртиптә Комиссия утырышы уздыру өчен нигез булырлык мәгълүмат кергәндә:

а) 3 көн эчендә Комиссия утырышы вакытын билгели. Шул ук вакытта, әлеге Нигезләмәнең 21 һәм 22 пунктларында каралган очраклардан тыш, Комиссия утырышы бу мәгълүмат кергән көннән жиде көннән дә сонрак вакытка билгеләнә алмый;

б) Комиссия аңа карата хезмәт тәртибенә таләпләр турында һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу хакында мәсьәләне караган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсенең коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи затына кергән мәгълүмат белән һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) әлеге Нигезләмәнең 12 пункты «б» пунктчасында күрсәтелгән затларны Комиссия утырышына чакыру турындагы үтенечен карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау (караудан баш тарту) турында карар кабул итә.

21. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы өченче абзацында күрсәтелгән гаризаны карау Комиссиясе утырышы, гадәттә, керемнәр турында, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында бирелгән мәгълүматлар тапшыруга билгеләнгән вакыт тәмамланганнан соң бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

22. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

23. Комиссия утырышы аңа карата хезмәт урынында үз-үзеңне тотуга карата таләпләрнең йә (яисә) мәнфәгатьләр каршылыкларын җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлеше турындагы мәсьәлә тикшерелә торган дәүләт хезмәткәре яисә Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан катнашында уздырыла. Дәүләт хезмәткәре яисә Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның әлеге мәсьәләне аннан башка гына карап тикшерү турында язма үтенече булганда, Комиссия утырышы аннан башка гына уздырыла. Әгәр дә дәүләт хезмәткәре (аның вәкиле) Комиссия утырышына килмәсә һәм дәүләт хезмәткәренең әлеге мәсьәләне аның катнашыннан башка гына хәл итү турында язмача үтенече булмаса, мәсьәләне карап тикшерү кичектерелә. Дәүләт хезмәткәре нигезле сәбәпсез кабаттан утырышка килмәсә, Комиссия дәүләт хезмәткәреннән башка әлеге мәсьәләне карау турында карар кабул итә ала. Әгәр дә дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче граждан (аның вәкиле) тору урынын алыштыру сәбәпле, ләкин Комиссия утырышы уздыру вакыты турында аңа хәбәр итүнең барлык чаралары да күрелгән очракта, Комиссия хезмәткәреннән башка әлеге мәсьәләне карау турында карар кабул итә ала.

24. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең яки Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасы биләгән гражданның (аның ризалыгы белән) һәм башка

затларның аңлатмалары тыңлана, дәүләт хезмәткәренә белдерелә торган дәгъваның асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

25. Комиссия әгъзаларының һәм аның утырышында катнашучы затларның аларга Комиссия эше барышында мәгълүм булган белешмәләрне таратырга хакы юк.

26. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «а» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре биргән керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең дөрес яисә тулы булуын билгеләргә;

б) Нигезләмәгә туры китереп, дәүләт хезмәткәре биргән, әлеге пунктның «а» пунктчасында аталган белешмәләр дөрес түгел һәм (яисә) тулы түгел икәнлеген билгеләргә. Бу очракта Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата анык җаваплылыкка тарту чарасы кулланырга тәкъдим итә.

27. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «а» пунктчасы өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу турында таләпләрне үтәгән дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенә дәүләт хезмәткәрен хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне бозуга юл куелмавы хакында кисәтергә яки аңа карата анык җаваплылык чарасы кулланырга тәкъдим итә.

28. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яки коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга, әгәр дәүләтнең бу оешма белән идарә итүе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, ризалык бирергә;

б) гражданга коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яки коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга, әгәр дәүләтнең бу оешма белән дәүләт идарә итүе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи

(хезмәт) бурычларына кергән булса, ризалык бирүдән баш тартырга һәм баш тартуны дәлилләргә.

29. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең үз хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирмәвенең сәбәбе объектив һәм әһәмиятле булып торуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең үз хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирмәвенең сәбәбе объектив һәм әһәмиятле булып тормавын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә әлеге белешмәләрне бирү чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәренең үз хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирмәвенең сәбәбе объектив һәм әһәмиятле булып тормавын һәм күрсәтелгән белешмәләрне бирүдән тайпылу ысулы булуын танырга. Бу очракта Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата анык җаваплылыкка тарту чарасы кулланырга тәкъдим итә.

30. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясенән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулык итүче сәбәпләрне объектив һәм нигезле дип тану турында;

б) «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясенән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулык итүче сәбәпләрне объектив һәм нигезле түгел дип тану турында. Бу очракта Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата анык җаваплылыкка тарту чарасы кулланырга тәкъдим итә.

31. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «г» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә күзәтчелек хакында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль

законның 3 статьясы 1 өлешендә аталган белешмәләр дөрес яисә тулы булуын билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килү-килмәүгә күзәтчелек хакында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 1 өлешендә аталган белешмәләр дөрес түгел һәм (яисә) тулы түгел икәнлеген билгеләргә. Бу очракта Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата анык җаваплылыкка тарту чарасы кулланырга һәм (яисә) чыгымнарны тикшерү материалларын прокуратура органнарына һәм (яисә) компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча башка дәүләт органнары бирергә тәкъдим итә.

32. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «а», «б», «г», һәм «д», пунктчаларында каралган мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, моңа нигезләр булганда, Комиссия әлеге Нигезләмәнен 26-31 пунктларында каралганнан башка карар кабул итә ала. Мондый карарны кабул итү нигезләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

33. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Идарәдә дәүләт хезмәткәре вазыйфасы биләгән граждан буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) әгәр коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр анын вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, аңа вазыйфа биләүгә яки коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирергә;

б) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләү яки коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкару (хезмәт күрсәтү) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елнын 25 декабрендәге ФЗ-273 номерлы Федераль законнын 12 статьясы таләпләре бозылуга китерә дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенә әлеге хәлләр турында прокуратура органнарына һәм хәбәр биргән оешмага мәгълүмат бирергә тәкъдим итә.

34. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

35. Комиссия карарларын үтәү өчен Идарәдә норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенең карарлары яисә йөкләмә проектлары әзерләнеп, тиешле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенә тәкъдим итәргә мөмкин.

36. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия башка карар кабул итмәсә) утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

37. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга утырышта катнашучы Комиссия әгъзалары кул куя. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карардан гайре, Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе өчен тәкъдим характерында була. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар мәҗбүри характерда була.

38. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышының вакыты, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) Комиссия утырышында каралучы һәр мәсьәләнең, ана карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу турында таләпләрне үтәве турындагы мәсьәлә каралучы дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы күрсәтелгән формулировкасы;

в) дәүләт хезмәткәренә куелучы дәгъвалар, аларны нигезләүче материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның куелган дәгъваларның асылы буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача бәян ителүе;

е) Комиссия утырышы уздыру өчен нигез булган мәгълүматның чыганагы, мәгълүматның дәүләт органына керү вакыты;

ж) башка белешмәләр;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

39. Комиссия карары белән риза булмаган Комиссия әгъзасы язмача рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри тәстә теркәп куелырга тиеш һәм аның белән дәүләт хезмәткәре танышырга тиеш.

40. Комиссия утырыш беркетмәсенен күчермәләре утырыш булган көннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенә җибәрелә, тулысынча яисә аннан өзекләр рәвешендә - дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары нигезендә башка кызыксынган затларга җибәрелә.

41. Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе Комиссия утырышы беркетмәсен карарга һәм киләчәктә үз компетенциясе чикләрендә дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында каралган җаваплылык чаралары куллану, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча карарлар кабул иткәндә анда булган тәкъдимнәрне исәпкә алырга тиеш. Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе язмача рәвештә аңа Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән соң бер ай эчендә Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында

комиссиягә хәбәр итә. Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенең карары Комиссиянең иң якындагы утырышында игълан ителә һәм тикшерүсез генә игътибарга алына.

42. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәре гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплина бозу билгеләре бар дип билгеләнгән очракта, бу хактагы мәгълүмат, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында каралган җаваплылык чаралары куллану турында мәсьәләне хәл итү өчен, Татарстан Республикасы дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе җитәкчесенә тапшырыла.

43. Комиссия дәүләт хезмәткәре тарафыннан административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре булган гамәлләр кылу фактларын (гамәл кылмау фактларын) ачыклаган очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлне кылу (гамәл кылмау) турындагы мәгълүматны һәм мондый фактны раслаучы документларны хокук куллану органнарына 3 көн эчендә, ә кирәк булганда – кичекмәстән тапшырырга бурычлы.

44. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яисә аңардан өзек аңа карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәве хакындагы мәсьәлә каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп куела.

45. Комиссия карарыннан аның секретаре имзасы һәм Идарә мөһере белән расланган күчермә Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, аңа кагылышлы әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданга кул куйдырып тиешле Комиссия утырышы уздырылган көннән соң килүче бер эш көненнән дә кичектермичә бирелә яисә аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча хәбәрнамәле заказлы хат белән җибәрелә.

46. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документация белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, утырышның көне, вакыты һәм урыны хакында мәгълүмат бирү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында тикшерү өчен бирелә торган материаллар белән таныштыру Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэмин итү бүлекчәсенең коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.